муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «Янгуловская средняя общеобразовательная школа имени Героя Советского Союза Г.Г. Гарифуллина» Балтасинского муниципального района Республики Татарстан

Утверждаю
Директор: /И.И.Зиганшин/
Приказ №77 от «31» августа 2022 года

# Рабочая программа

# ДОО «Хыял»

Принято на заседании
педагогического совета
(Протокол № 2
от «31» августа 2022 г.)

2022 – 2023 учебный год

**Аңлатма язуы.**

Балалар оешмалары- иҗтимагый хәрәкәтләрнең бер өлеше. Алар яшь буынны тормышка әзерләүдә, аның мәнфәгатьләрен һәм хокукларын яклауда зур әһәмияткә ия.

Үзара берләшергә омтылу-балаларга һәм яшүсмерләргә хас табигый күренеш. Төрле төркемнәр, компанияләр, командалар, оешмаларга тупланып, алар үзләренең белемнәрен, көчләрен һәм мөмкинлекләрен берләштерәләр, аларны уен, танып белү, хезмәт белән бәйле максатларга юнәлтәләр. Бигрәк тә 10-11 яшьтәгеләр иҗтимагый активлыклары, тормыштагы уңай һәм тискәре якларны танып белергә, төрле эшчәнлек тә катнашырга әзер торулары белән аерылып торалар. Шуңа күрә аларның үз оешмалары булуы бик мөһим. Укучылар үз оешмаларын өлкәннәрдән башка гына төзи алмыйлар. Өлкәннәр үзләре дә шул оешмаларга әгъза булып кереп, балалар белән бергә төрле эшчәнлектә катнашып, шул ук вакытта алар эшчәнлегенә педагогик җитәкчелек итәргә мөмкин.

Безнең Яңгул урта мәктәбендә балалар оешмасы "Хыял"исемен йөртә. Оешмага 2-11 сыйныф укучылары керә. 2кл.тан - 4кл.ка кадәр "эзтабарлар", 5кл.тан - 8кл.ка кадәр "варислар".

Без үз эшебезне "Мирас юлы" , «Эзтабар юлдашы», «Галстуклы ил» программасы нигезендә алып барабыз. Балалар оешмасы ул, һәркемнең күңеленә охшаган эшне сайлап алырга һәм бер-берең белән ныграк аралашырга, үзеңнең талантыңны ачарга ярдәм итә. Шулай ук укучыларга тәрбия, тормыш күнекмәләре бирүдә билгеле бер эш башкара. Оешмада тәрбия процессының сыйфат һәм дәрәҗә күрсәткече булып укучыларның киң мәгънәдәге әхлак тәрбиясе тора. Укучыларның әхлаклылыгы, тәрбиялеге – оешманың бурычы да, күрсәткече дә. Шәхеснең һәрьяклап үсеш дәрәҗәсен чагылдырган, җәмгыять өчен файдалы булган сыйфатлар җыелмасы тәрбияләү – төп бурыч булып тора. Шушы план белән эшләгәндә әхлаклылыкны түбәндәге күрсәткечләр буенча билгеләргә тырышабыз: патриотлык, интернацио нальлек, бердәмлек, уңганлылык, хезмәтне ярату, намуслылык, сакчыллык, дисци плиналылык, активлык, эстетик һәм физик үсеш.

Эшләү дәверендә түбәндәге чаралар үткәрү күз алдында тотыла: музейларга сәяхәт, викториналар, әдәби-музыкаль кичәләр, диспутлар, конференцияләр, очрашулар, конкурслар, ярышлар

## Программаның актуальлеге:

Бу программа укучыларда халкыбызның борынгыдан килгән гореф-гадәтләренә, туган як тарихына хөрмәт хисе тәрбияләү, үзеңнең милләтең, мәдәниятең белән горурланырга өйрәтү, чын патриотлар итеп тәрбияләүгә юнәлтелгән

**Программаның максаты:**

Мөстәкыйль тормыш алып барырлык, рухи һәм физик яктан сәламәт, үзендә кешелеклелек сыйфатын, туган як кыйммәтләрен туплаган, туган ягын яратучы шәхес тәрбияләү.

**Программаның бурычлары:**

-Укучыларның иҗади сәләтләрен ачу һәм үстерү.
-Укучыларда патриотик,әхлакый-эстетик,экологик культура тәрбияләү.
-Туган як тарихын өйрәнү,өлкәннәрне,борынгы гореф-гадәтләрне хөрмәт итәргә өйрәтү һәм традицияләрне саклау.
-Укучыларның лидерлык сәләтләрен үстерү.

**Көтелгән нәтиҗә:**
Программа укучыларда түбәндәге сыйфатларны булдыруны күздә тота:
- Гармонияле үсеш, күпкырлы интеллект, югары дәрәҗәдәге культура, башка кешене шәхес итеп кабул итү сәләте;
- Социаль җаваплылык, ил язмышы өчен кайгыртучанлык, әхлаклылык һәм патриотлык, гомумкешелек кыйммәтләре һәм нормаларына ия булу;
- Заманга, тормышка адаптацияләшү, төрле тормыш ситуацияләрендә катгый карар кабул итү һәм үз эшчәнлегеңә бәя бирү сәләте;
- Лидерлык сыйфатларын, үз-үзеңне үстерү, камилләштерүгә сәләтлелек;
-Аралашу, үз-үзеңне тоту һәм көнкүреш культурасы, эстетик зәвык;
-Башка кешенең фикерен, гореф-гадәтләрен, динен хөрмәт итү, толерантлык;
-Хезмәт сөючәнлек, мөстәкыйль тормышка әзерлек;
-Ата-ананы хөрмәт итү, гаиләне ярату, миһербанлык, гуманлылык.

**Программаның вакыты:** программа 3 уку елына исәпләнгән

**Программада катнашучылар:** 2-8 сыйныф укучылары- Татарстан Варислар Берлеге членнары

**Татарстан Варислар Берлегенең девизы: -** “Һәрвакыт әзер!”
**Лозунгысы** - “Көн саен яхшылык кыл!”
**“Хыял” балалар оешмасының девизы:** “Хыял дөньясында яшә, белем диңгезендә йөз!”

**Эзтабарлар: 2-4 класс укучылары керә;**
Эзтабар кагыйдәләре:
-Эзтабар куркусыз
-Эзтабар кыю
-Эзтабар намуслы
-Эзтабар тагын да яхшырак булырга омтыла
**Варислар: 5-8 класс укучылары керә;**
Варисларның законнары:
1. Варис республикасына булыша, аның лаеклы гражданины булырга тырыша.

2. Варис дөреслек, хаклык өчен кыю тора.
3. Варис тугрылыклы иптәш, олыларга һәм кечеләргә булыша, беркемне дә авырлыкларда ялгыз калдырмый.
4. Варис күп белергә,көчле һәм җитез булырга омтыла.
5. Варис табигатьне,туган ягын, мәдәниятне уяу саклый

**Программаның бүлекләре:**

Эзтабарлар блогы: - “Минем гаиләм”
-“Минем туган авылым”
- “Минем республикам”

Варислар блогы: -“Батырлардан үрнәк ал”
-“Әйләнә-тирәдәгеләргә битараф булма”
-“Безне бөек эшләр көтә”

**Программаның эчтәлеге:**
**Эзтабарлар блогы**
1 ел:

- **“Минем гаиләм” бүлеге**
  **Бүлекнең бурычлары:**
  - балалар оешмасында бердәм эшчәнлеккә өйрәтү;
  -гаилә традицияләрен өйрәнү;
  -әйләнә тирәдәгеләрне хөрмәт итәргә өйрәтү.

**Эш төрләре**: 15 сентябрь- ТВБ көне, 1 октябрь- өлкәннәр көне, 27 ноябрь- Әниләр көне, “ мин-эзтабар” бәйрәме,15 май- Гаилә көне, “гаиләм традицияләре”-презентацияләр парады, “безнең гаилә”- рәсем күргәзмәсе, “әти, әни,мин- спорт гаиләсе”-күңелле стартлар, “гаиләбез профессияләре”- төрле профессия кешеләре белән очрашулар, “гаиләбез ядкаре”- мини сочинениеләр парады, “безнең өйдә - өлкәннәр”-фотокүргәзмә, “гаиләм-шәҗәрәсе”- шәҗәрәләр парады.

2 ел:

- **“Минем туган авылым” бүлеге**
  **Бүлекнең бурычлары:**
  - балалар оешмасында бердәм эшчәнлеккә өйрәтүне дәвам итү;
  -эзтабарларны туган авылыбызның традицияләре белән таныштыру;
  -авылыбызның матурлыгын күрә белергә өйрәтү

  - төрле чараларда катнашырга өйрәтү

**Эш төрләре**: 5 октябрь- Укытучылар көне, 21 март- Нәүрүз коне, 22 апрель- Җир көне, “авылым буйлап сәяхәт”- авыл белән танышу экскурсияләре, мәктәп музеена сәяхәт,экспонатлар туплау, авылыбызда урнашкан учреждениләргә сәяхәт, “табигать һәйкәлләре”- алар турындагы язмалар белән танышу, авылыбызның өлкәннәре белән

очрашулар, авылыбызның спортсменнары белән очрашулар, “Минем туган авылым иң матуры!”-фотоконкурс уздыру, табигать коагына- җәяүле походлар оештыру.

3 ел:

- **“Минем республикам” бүлеге**

  **Бүлекнең бурычлары:**

  - балалар оешмасында эшләү теләге формалаштыру;

  -эзтабарларны республикабызның символикасы, традицияләре белән таныштыру;

  - варислар сафына керү өчен әзерләү

**Эш төрләре**: 15 сентябрь- ТВБнең туган көнен уздыру, 26 апрель- Г.Тукай туган көнне билгеләп үтү, “Республикабыз бәйрәмнәре”- презентацияләр парады, “нәни сабантуй” уздыру, “син Татарстан, Россия символларын беләсеңме?” –викторина, гимн җырлыйбыз- Татарстан гимнын өйрәнү. “Татарстанга сәяхәт”-уен-сәяхәт, районыбызда урнашкан музейларга экскурсияләр оештыру, “Мин туган ягымны яратам”- фотолар парады, “туган авыллым-Татарстанның бер кисәге”- рәсем күргәзмәсе, варислар бәйрәме уздыру.

**Варислар блогы**

1 ел:

- **“Батырлардан үрнәк ал!” бүлеге**

  **Бүлекнең бурычлары:**

  - балалар оешмасы эшәнлегендә катнаштыру;

  - сугыш каһарманнары белән таныштыру;

  - туган ягыңны ярату хисе уяту

**Эш төрләре**: 15 сентябрь- ТВБнең туган көне, 4 ноябрь- Халыкара Бердәмлек көне, 9 декабрь- Ватан геройлары көне, 15 февраль- Интернационалист сугышчылар көне, 9 май- Җиңү коне, “исәннәрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел!” һәйкәлләргә рейдлар уздыру, чәчәкләр кую, мәктәбебезнең “Сугышчан дан” музеена экскурсия, “семейная фотохроника” конкурсында катнашу, хезмәт батырлары белән очрашулар уздыру, “минем бәхетле балачагым”- рәсем парады, “Гаиләбездә- сугыш батырлары”- сочинениеләр конкурсы, “сугыш чоры-пионерлары нинди булган”- очрашу-кичә(шул чор пионерлары белән очрашу), “мин-варис” вариска кабул итү тантанасы.

2 ел:

- **“Әйләнә-тирәдәгеләргә битараф булма!” бүлеге**

  **Бүлекнең бурычлары:**

  - әйләнә-тирәдәгеләргә ярдәм итү теләге уяту;

  - буыннар бәйләнешен сакларга өйрәтү;

  - туган як традицияләренә битараф булмаска өйрәтү

**Эш төрләре**: 15 сентябрь- ТВБ көне, 1 октябрь- өлкәннәр , 5 октябрь –укытучылар көне, 22 апрель- җир көне, 19 май- пионер туган көн, “минем мәктәбем -иң чистасы”- өмә уздыру, тимурчылык рейдлары уздыру, котлау акцияләренә чыгу, “эзтабарларга ярдәм итик”- бәйрәм котлаулары ясарга, яңа ел маскалары ясарга булышу, шәфкатьлелек ярминкәләре уздыру, “киемнәргә икенче сулыш”- тотылган киемнәр җыеп хәйрия кибетенә тапшыру, “нәни сабантуй” уздыру.

3 ел:

- **-“Безне бөек эшләр көтә” бүлеге**
  **Бүлекнең бурычлары:**
  - Һөнәр сайларга юнәлеш бирү;
  - сәламәт тәндә- сәламәт фикер;
  - туган ягыңны ярату хисе тәрбияләү.

**Эш төрләре**: 15 сентябрь- ТВБ көне, 1 октябрь- өлкәннәр , 4 ноябрь-бердәмлек көне, 20ноябрь -балалар конвенциясе көне, 19 май- пионер туган көн, “безнең гаилә пионерлары”- гаилә истәлекләрен туплау, “һөнәр сайлау- җаваплы эш”- төрле профессия вәкилләре белән очрашу-кичәләр, “мин кем булырга телим”- түгәрәк өстәл, “Начар гадәтләрдән ерак торыйк”- театральләштерелгән тамаша, “без спорт яклы”- акция, “һөнәрләр тукталышы”- төрле профессияләр белән таныштыру, авылыбызда урнашкан учреждениеләргә экскурсия.

**Файдаланылган әдәбият**

1.Галстучная страна.Программа
2.К истокам гражданственности. Казань:2002, часть1-Казань:2003, часть2-Казань:2003
3.”Эзтабар юлдашы” программасы
4.”Мирас юлы” програмасы